**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Татар Шуганы авыл җирлеге Советы**

Татар Шуганы авылы №99 «28 » ноябрь 2023 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Советының 24.11.2014 ел №119 «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында (04.08.2015 №150, 04.08.2017 №60, 09.10.2018 №115, 25.06.2019 №141, 05.11.2019 №152, 02.10.2020 №11, 15.03.2021 №21, 11.08.2021 №33 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 78 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2023 елның 31 июлендәге 389-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Татар Шуганы авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Советының 24.11.2014 ел №119 «Җир салымы турында» карарына (04.08.2015 №150, 04.08.2017 №60, 09.10.2018 №115, 25.06.2019 №141, 05.11.2019 №152, 02.10.2020 №11, 15.03.2021 №21, 11.08.2021 №33 карарлар редакциясендә)түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«2) Кадастр бәясенең 0,3 проценты-торак фонд һәм торак-коммуналь комплексының инженер инфраструктура объектлары урнашкан җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына туры килмәгән объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктан тыш) яки торак төзелеше өчен сатып алынган (эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш).»

2. Әлеге карар район газетасы “Маяк”та басылып чыкканнан соң бер ай узгач кына үз көченә керә һәм 2024 елның 01 гыйнварыннан җир салымын исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны «Маяк» район газетасында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының

Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aznakayevo.tatar.ru урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Хэертдинов М.Ш.

